КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2020 ел, 5 декабрь г.Казань № 1096

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасында өлкән яшьтәге гражданнарны һәм инвалидларны озак вакыт карау системасын оештыру турында» 2019 ел, 23 май, 432 нче карары белән расланган 2020 елда социаль хезмәт күрсәтүгә мохтаҗ дип танылган өлкән яшьтәге гражданнарны һәм инвалидларны озак вакыт карау системасын оештыруга юнәлдерелгән чараларны тормышка ашыруны финанслар белән тәэмин итү кагыйдәләренә үзгәреш кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасында өлкән яшьтәге гражданнарны һәм инвалидларны озак вакыт карау системасын оештыру турында» 2019 ел, 23 май, 432 нче карары белән (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2020 ел, 28 гыйнвар, 32 нче; 2020 ел, 2 март, 161 нче; 2020 ел, 17 апрель, 303 нче; 2020 ел, 3 сентябрь, 787 нче, 2020 ел, 22 сентябрь, 854 нче карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) расланган 2020 елда социаль хезмәт күрсәтүгә мохтаҗ дип танылган өлкән яшьтәге гражданнарны һәм инвалидларны озак вакыт карау системасын оештыруга юнәлдерелгән чараларны тормышка ашыруны финанслар белән тәэмин итү кагыйдәләренә, 7 нче пунктның өченче абзацында «хуҗалык товарлары» сүзләреннән соң «, җиһазлар» сүзен өстәп, үзгәреш кертергә.

2. Бу карарның гамәлдә булуы 2020 елның 1 сентябреннән барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә кагыла дип билгеләргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин